**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“26” ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан,1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Комыргуҗа авылы зиратын чистарту (агач кису, үлән чабу);
- Комыргуҗа авылында территорияне чистарту үлән чабу, транспорт хезмәтләре күрсәтү;
- Комыргуҗа авылы паркы территориясендә газон чабу (эш һәм хезмәт өчен түләү);
- урам яктырту (лампаларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) лампалар сатып алу;
- Комыргуҗа авылындагы парк территориясенә видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру (эш һәм хезмәт өчен түләү);барлык җайланмалары белән.
- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу(эш һәм хезмәт өчен түләү);
- Комыргуҗа авылы урамнарында урнашкан янгын гидрантлары өчен баганалар сатып алу.

2022 елга гражданнар җыены буенча җыелган (экономияләнгән) үзара салым акчасын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

- Комыргуҗа авылында (Тукай урамына) юл салу өчен вак таш сатып алу.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.